КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 20 июнь г.Казань № 504

Татарстан Республикасы Хөкүмәтендә
проект эшчәнлеген оештыру турында

Татарстан Республикасы Хөкүмәтендә проект эшчәнлеген гамәлгә ашыру, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарында проект эшчәнлеге белән идарә итү органнарын формалаштыру максатларында, шулай ук Россия Федерациясе Президентының «2024 елга кадәр чорга Россия Федерациясен үстерүнең илкүләм максатлары һәм стратегик бурычлары турында» 2018 елның 7 маендагы 204 номерлы Указы һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтендә проект эшчәнлеген оештыру турында» 2018 елның 31 октябрендәге 1288 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгәннәрне расларга:

Татарстан Республикасы Хөкүмәтендә проект эшчәнлеген оештыру турында нигезләмә (алга таба – Нигезләмә);

Татарстан Республикасы Хөкүмәтендә проект эшчәнлегенең функциональ структурасы;

Төбәк проект офисы составы.

2. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарына, Нигезләмәгә таянып, проект эшчәнлеген оештыруны тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына, Нигезләмәгә таянып, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегендә проект эшчәнлеген оештыруны тәкъдим итәргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин